

Ләмберә районы республикабызда татарлар районы дип йортелә, чонки биредә кvплəп татар миллəтле халкыбыз яши. Хормəткə лаек тагы бер кеше турында сvзебез. Анын турында «Призыв» яза.
Ләмберә районы Шербаково авылы автомобиль юлынын беренче тозvчесе турында берничə сvз əйтергə сылтау бар. Бу Камиль Атаулла улы Максутов. Максутовлар нəселен авылда бик хормəт итəлəр. Монда намуслылыгы, диндарлыгы, игелеге белəн аерылып торган нəсел башлыгы Атаулланы искə тошерv урынлы булыр иде. Авырлык Максутовларны зур ил шəһəрлəренə таратты. Атаулла vзе вакытлыча Мəскəv олкəсендə яшəгəн. Лəкин ничек кенə булмасын, кvплəре бу шартларда сизелерлек дəрəҗəгə һəм вазифаларга ирешкəннəр. Шулай да Максутовлар гаилəсендə зур игътибар бирелгəн тəрбия һəм белем сизелде. Әйтик, Атаулла улы Ахать Фрунзе шəһəрендə гаять зур житештерv берлəшмəсенен баш хисапчысы, СССР Тышкы эшлəр министры Андрей Андреевич Громыко секретаре булган. Камиль Атаулла улы да, яхшы тормыш мəктəбе узып, гади эшче-тозvче буларак, районда гына тvгел, ботен республикада да билгеле кеше. Ул Мəскəv олкəсенен Ногинск шəһəрендə яшəгəндə флотта хезмəт итəргə чакырыла. Дvрт ел хезмəт иткəч, тагын Ногинскка кайта. Әмма Камильнен кvнеле һаман да туган иленə тарта булганын гаилəсе еш искə тошерə. Хыялы тормышка аша: туган ягына кайтып хезмəт итə башлый.
Камиль Атаулла улы Максутов Саранскида тектоник хəрəкəтлəр булган вакытта, vсеш алган индустриаль шəһəргə əверелгəн чакта ук тозvче булып эшлəгəн. Ул 1957 елдан шəһəрнен кvп кенə заводларын – кабель, инструменталь, экскаватор заводларын този. Торле яклап vсеш алган шəһəрдə зур масштаблы торак тозелеше ачыла. Биредə дə Камиль Атаулла улы монтажчылар бригадасын житəклəп зур эштə vзенен олешен кертə. Аена 27 йорт тозеп тапшыралар! Шунысын да билгелəп vтəргə кирəк: ул вакытта «Хезмəттə - хормəт» сvзлəре сойлəм əйлəнмəсе генə тvгел, ə анын артында реаль эчтəлек тора иде. Шуна да К.А.Максутовка Мəскəvдə СССР ВЦСПС рəисе югары бvлəк тапшыра. Ул - СССР Дəvлəт премиясе лауреаты. Ташламалар буенча бу исем, могаен, Социалистик Хезмəт Герое исеме белəн бер дəрəҗə булгандыр. Лəкин эш остен-леклəрдə, ташламалар- льготаларда тvгел. Камиль Атаулла улы Максутов якташлары Щербаклыларга, vз исеменен биеклегеннəн, тормыш проблемасын – юл

vткәрv мәсьәләсен хәл итәргә ярдәм итә алган. К.А.Максутов Саранск йорт тозv комбинатында тозvчеләр-монтажчылар бригадасын житәкләгән чакта, Щербакта юл тозелеше проектын гамәлгә аштыра – «пробивает». Юл тозелешенә бетон плитәләр бvлеп бирv очен рохсәт ала һәм юлны тозиләр. Озакламый юлны ачып та жибәрәләр. Тик монда бер нюансны искә тошерәсе килә: план буенча юл Мәскәv трассасыннан авыл vзәгенә кадәр барган, ә бригадирнын абруе (авторитеты) ярдәмендә, тозvчеләр остәмә плитәләр ала һәм юлны ботен авыл буйлап салып чыгалар. Элекке Щербактагы юл, 40 еллык тәнәфестән сон, бvген янадан тозелә, дип әйткән идек. Һәм (ышанабыз!) быел тозекләндереләчәк. Тик юлны ачу тантанасында якташлары трассанын беренче салучысын, СССР Дәvләт премиясе лауреаты Камиль Атаулла улы Максутовны һичшиксез искә алачаклар.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**